РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Нижний Услон ______________

14 25.08

Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып,Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау хакында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Күчемсез милек объекты адресын бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1-нче кушымта).

1.2. Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең чикләрен килештереп, кадастр исәбенә кую максаты белән муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.4. Йорт биләүгә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә җир кишәрлегенә белешмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.6 Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслаучы муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.7. Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.8. Гражданнар милкенә торак урыннарны тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

1.9. Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (8 нче кушымта).

1.10. Васыятьләр таныклыгы буенча һәм ышанычнамәләр таныклыгы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта).

2. “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында”гы 12 нче елның 30 мартындагы №12 Түбән Ослан авыл җирлегенең башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек объектына адрес бирү, үзгәртү һәм адресны гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең 20.11.2015 ел №14 карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында җирлекнең мәгълүмат һәм стендларында әлеге карарны урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.З.Шәйдуллин